Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның 20 мартыннан № 138

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Большесалты авыл җирлеге Советы тарафыннан 2023 елның 3 мартындагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Генераль планын кушымта нигезендә электрон чыганакта расларга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Генераль планын территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/).

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге советына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында элек кабул ителгән карарның үз көчен югалткан дип таныргa тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н. А. Вазыйхов